**Шушмабаш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе**

07 июнь 2019 ел Шушмабаш авылы 10 сәг.00 мин.

**Үткәрү урыны**: Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1в,
**Катнаштылар**:51 кеше
**Рәислек итүче**: - Шушмабаш авыл җирле башлыгы
Сәгыйтов Вәзир Вазыйх улы
**Тыңладылар:**
Шушмабаш авыл җирле башлыгы Сәгыйтов Вәзир Вазыйх улы:
Хәерле көн, Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башлыгының 2019 елның 26 мартындагы 1 номерлы карары нигезендә, бүген бездә Шушмабаш авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрелә.
**Гавами тыңлаулар үткәрү өчен җаваплы итеп** җирлек башлыгы – Сәгыйтов Вәзир Вазыйх улы билгеләнде.
**Секретарь:** Әхмәтов Рафаэль Коттус улы — 7 нче номерлы округ депутаты.

Шушмабаш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 30-34 ст., "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль нигезендә башкарылды.

Шушмабаш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча гавами тыңлаулар датасы, карарлар проекты турында мәгълүмат Татарстан Республикасы рәсми мәгълүмат порталында, түбәндәге адреслар буенча авыл җирлеге стендларында урнаштырылды: ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1б; ТР, Арча районы, Носы авылы,. Татарстан урамы, 45

Шушмабаш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча гавами тыңлаулар ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1в адресы буенча үткәрелә. Гавами тыңлаулар үткәргәнче, Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең ПЗЗ проекты буенча язма кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кермәде. 2019 елның 06 апреленнән 06 июненә кадәр Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең ПЗЗ проекты буенча язма һәм телдән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү срогында шулай ук бернинди искәрмәләр дә, тәкъдимнәр дә кермәде.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре муниципаль берәмлекләр территорияләрен тотрыклы үстерү, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклау өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелешен зоналаштыруга карый. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү яңа Генераль планны раслауга, РФ Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертүгә бәйле.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре үз эченә ала: аларны куллану һәм әлеге кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе; шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы; шәһәр төзелеше регламентлары.

Сәгыйтов Вәзир Вазыйх улы: Сораулар бармы? Гавами тыңлаулар үткәрү барышында кисәтүләр булмады, кергән тәкъдим игътибарга алыначак. Әгәр дә сораулар булмаса, гавами тыңлаулар узган дип санала.

Гавами тыңлаулар
үткәрү өчен җаваплы — Сәгыйтов Вәзир Вазыйх улы

Секретарь — Әхмәтов Рафаэль Коттус улы